Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы
Түбән Үрәс авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

14 март, 2025 ел
№15

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү проекты турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә муниципаль берәмлек Уставы нигезләмәләрен гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Янил Түбән Үрәс авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Түбән Үрәс авыл җирлеге Советы карары проектын хупларга (1 нче кушымта).

2. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 28 гыйнварындагы 2 номерлы Кукмара шәһәре Советы карары нигезендә «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Түбән Үрәс авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрергә.

3. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү һәм аның буенча фикер алышуда гражданнарның катнашуы турында» Түбән Үрәс авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен расларга (2 нче кушымта).

4. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

Сафаров В.Г. – комиссия рәисе,
Карпова В.А. – комиссия әгъзасы,
Шамеев Р.Х. – комиссия әгъзасы.

Гордеева Г.И. – комиссия әгъзасы,

Павлова Л.Н. – комиссия әгъзасы.

5. Билгеләргә:

5.1. Гавами тыңлаулар үткәрү вакыты – 07.04.2025.

5.2. Гавами тыңлауларны үткәрү вакыты – 18.00 сәгать.

5.3. Үткәрү урыны – Вахитов авыл мәдәният йорты бинасы, адресы: ТР, Кукмара районы, Түбән Үрәс авылы, Парков ур., 6 й.

6. Эшче төркемгә, ачык тыңлауларда кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, карар проектын эшләп бетерергә һәм Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлеге Советы утырышында карарга кертергә.

7. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Интернет челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында http://kukmor.tatar.ru урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Түбән Үрәс авыл җирлеге башлыгы /В.Г. Сәфәров/

ОГРН 1021607753133
ИНН 1623002015

Түбән Үрәс авыл җирлеге
Советының 2025 елның 14
мартындагы 15 номерлы
карарына 2 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Түбән Үрәс авыл җирлеге Советы карары проектына гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе

1. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проектына тәкъдимнәр Түбән Үрәс авыл җирлеге Советына кертелә адресы: ТР, Кукмара районы, Түбән Үрәс авылы, Г.Ахметов ур., 39 й., үрнәк буенча төзәтмәләр таблицасы рәвешендә язма формада:

| т/б № | Статья, пункт, пунктча | Карар проекты тексты | Төзәтмә тексты | Төзәтмәләрне исәпкә алып, проект тексты | Төзәтмә авторы (Ф.И.А, адресы, телефоны, эш (уку) урыны |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Тәкъдимнәр эш көннәрендә 8 сәгать 00 минуттан 16 сәгатькә кадәр карар игълан ителгән көннән бер ай эчендә кабул ителә.

2. Гавами тыңлауларда чыгыш ясау хокукы белән катнашу өчен гаризалар шәхсән яки почта аша: ТР,Түбән Үрәс ав., Г.Ахметов ур., 39 йорт (конвертта «Устав турында фикер алышу» яки «гавами тыңлаулар» дигән тамга белән).

Гаризалар гавами тыңлаулар үткәрү датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча, эш көннәрендә 8 сәгать 00 минуттан 16 сәгатькә кадәр кабул ителә.

3. Гражданнарның тәкъдимнәре Түбән Үрәс авыл башкарма комитеты Секретаре тарафыннан теркәлә һәм, карау өчен, Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлеге башлыгына тапшырыла.

Түбән Үрәс авыл җирлеге башлыгы /В.Г. Сәфәров/